**Манзарас авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

**2022 елның 21 сентябреннән** **№ 23**

Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлегенең Манзарас авылы торак пунктында «Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлегенең Манзарас авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 15 ноябрендәге 1 номерлы Манзарас авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Манзарас авыл җирлеге Уставының 20 ст. нигезендә Манзарас авыл җирлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. 2022 елның 3 октябренә 10 сәгать 00 минутка беренче этапта, 2022 елның 3 октябренә 13 сәгать 00 минутка икенче этапта, 2022 елның 3 октябренә 15 сәгать 00 минутка өченче этапта, 2022 елның 3 октябренә 18 сәгать 00 минутка дүртенче этапта «Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлегенең Манзарас авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 15 ноябрендәге 1 номерлы Манзарас авылы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Манзарас авылы, Яшьләр урамы, 18а адресы буенча урнашкан Мәдәният йортында уздырырга.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлегенең Манзарас авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 15 ноябрендәге 1 номерлы Манзарас авылы гражданнар җыены карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертү белән килешәсезме:

- 2 пунктка түбәндәге эчтәлекле яңа абзацларны өстәргә:
- Манзарас авылының ТАССРның 90 еллыгы урамында су белән тәэмин итү системаларын төзү һәм ремонтлау, проект-смета документациясен эшләү, техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Манзарас авылының ТАССРның 90 еллыгы урамында янгын гидранты һәм комплектлау материаллары сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документациясен эшләү;
- Парковка урыннарын төзү һәм ремонтлау, проект-смета документациясен эшләү, техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Манзарас авылының Яшьләр урамында тротуар төзү һәм ремонтлау, проект-смета документациясен эшләү, техник күзәтчелекне тормышка ашыру?

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлеге Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырырга, шулай ук аны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Җирлек башлыгы Р.Г. Хәбибуллина